КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 август г.Казань № 933

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Транспорт чараларын мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) файдалануга яңадан җиһазландыру эшләрен башкаручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә яңадан җиһазландыруны башкаручы затлар тарафыннан күрсәтелгән эшләргә транспорт чаралары хуҗаларына ташламалар бирү белән бәйле алынмаган керемнәрен кире кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 21 июнь, 484 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 1 ноябрь, 1035 нче; 2022 ел, 10 сентябрь, 977 нче; 2023 ел, 10 май, 582 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Транспорт чараларын мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) файдалануга яңадан җиһазландыру эшләрен башкаручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә яңадан җиһазландыруны башкаручы затлар тарафыннан күрсәтелгән эшләргә транспорт чаралары хуҗаларына ташламалар бирү белән бәйле алынмаган керемнәрен кире кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә, 3 пунктның дүртенче абзацындагы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Транспорт чараларына кысылган табигый газ салу объектларын төзүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 28 октябрь, 1008 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 6 октябрь, 1074 нче; 2023 ел, 10 май, 582 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган

Транспорт чараларына кысылган табигый газ салу объектларын төзүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә, 3 пунктның өченче абзацындагы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин